Татарстан Республикасы

АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

«УРМАНДӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

№ 6

02.11.2021 ел

«Татарстван Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең Сосновка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Урмандәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә
КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең Сосновка поселогында яшәүче гражданнар өчен 2021 елның 12 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләгә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең Сосновка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән, Сез килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
- Сосновка поселогына вак таш, ШПС сатып алу (сатып алу, ташу)
- Юлларны кышкы карап тоту (килешү буенча эшләр өчен түләү).

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп);
- торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыеннарын оештыру һәм үткәрү өчен Урмандәй авыл җирлеге башкарма комитетына җаваплылык йөкләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
5. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Урмандәй авыл җирлеге башлыгы: В.З.Николаев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРМАНДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ